**Ветераннарыбызга Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов исеменнән котлау открыткалары, бәйрәм күчтәнәчләре тапшырылды**

Быел без Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан алып, 79нчы тапкыр Җиңү бәйрәмен тантаналы төстә бәйрәм итәбез. Илебезгә ирек һәм тынычлык яулап алучыларга карата йөрәкләрдәге рәхмәт һәм хөрмәт хисләре шушы еллар эчендә кимемәде, ә киресенчә гел арта гына бара. Ветераннарыбызның тиңдәшсез батырлыгы, фидакарь хезмәте, ил өстенә яу килгәндә районыбызның батыр ул-кызларының да тере калкан булып, дошманга каршы күтәрелүләре чиксез каһарманлык үрнәге, без алар белән чын күңелдән горурланабыз. Бүгенге көндә районыбызда 102 тыл хезмәтчәне, 27 Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол калган хатыннары гомер кичерә. Аларның һәркайсына Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов исеменнән котлау открыткалары, бәйрәм күчтәнәчләре тапшырылды.

